Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

“ 16 ” ноябрь 2018 ел № 2

## 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Арча шәһәре Советының 13.09.2018 елдагы 99 номерлы карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә:

1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты-03.12.2018, 17.00 сәгатьтә;

2.2. Уздыру урыны-Арча шәһәре Башкарма комитетының административ бинасы;

2.3. Тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр тәкъдим ителә торган адрес: ТР, Арча районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт (эш көннәрендә-08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 03.12.2018 елга кадәр (тел. 3-16-25).

3. Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тәртип һәм карар белән билгеләнгән срокларда күрсәтелгән әлеге мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

И.Г. Нуриев